Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
« Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иж-Бубый торак
пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**12.11.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта һәм 15 сәгать 00 минутта “Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәкләрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1) Иж-Бубый торак пунктының зиратының коймаларын ремонтлау, яңаларын кору, төзекләндерү (зират территориясендә кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган авария хәлендәге һәм корыган агачларны кисү; Иж-Бубый торак пункты зиратын төзекләндерү, коймалар кору өчен материаллар сатып алу һәм башка чыгымнар);

2) Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү (газоннарны һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

3) Иж-Бубый торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар сатып алу һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларга түшәү өчен вак таш сатып алу һәм салу; автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар;

5) Иж-Бубый торак пунктында яшәүчеләрне су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка

инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрен төзү һәм ремонтлау, торак пунктны су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

6) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа сатып алу; янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?” дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 475 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 244 кеше, бу 51,3% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 229 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен – 15 катнашучы.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2026 елда Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Боубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә акчалар кертергә. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчасын кертүдән азат ителә:

- махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзалары (ата-аналар, ир белән хатын),
- I группа инвалидлар,
- хәрби хезмәт вакытында авыру алган инвалидлар,
- өлкән яшьтәге ялгыз (80 яшькә җиткән)гражданнар,
- көндезге бүлектә укучы студентлар,
- Россия Армиясендә хезмәт итүче затлар,
- иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлар.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1) Иж-Бубый торак пунктының зиратының коймаларын ремонтлау, яңаларын кору, төзекләндерү (зират территориясендә кешеләрнең гомеренә

һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган авария хәлендәге һәм корыган агачларны кисү; Иж-Бубый торак пункты зиратын төзекләндерү, коймалар кору өчен материаллар сатып алу һәм башка чыгымнар);

2) Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү (газоннарны һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

3) Иж-Бубый торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар сатып алу һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларга түшәү өчен вак таш сатып алу һәм салу; автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар;

5) Иж-Бубый торак пунктында яшәүчеләрне су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрен төзү һәм ремонтлау, торак пунктны су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

6) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа сатып алу; янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

4. Карарны Иж-Бубый авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Ваһапов